Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаятенә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2022 елның 27 мае

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Ф.С. Мусин, Э.М. Мостафина, Г.Л. Удачина, М.М. Хәйруллин составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче

абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган норматив хокукый нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья Г.Л. Удачина мәгълүматын, яклар — гражданин Ч.В. Мәҗитов, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының юридик бүлеге әйдәүче консультанты Р.Ж. Асьмаева аңлатмаларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары) 2 пункты белән, әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә

акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең (алга таба шулай ук — Нигезләмә) 9.11 пункты белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның (алга таба шулай ук — 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымта) «а» пункты белән аларның үзара бәйләнешендә үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Әлеге эш буенча тыңлаулар барышында мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән үзенең конституциячел хокуклары бозылуын күрсәтеп, шулай ук әлеге карарның 2.1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми дип тану үтенече белән тулыландырып, үз таләпләрен төгәлләштерде.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының шикаять белдерелә торган 2 пунктындагы икенче абзацында түбәндәгеләр билгеләнгән: пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның 31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга, мөрәҗәгать итү көненә уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэминителеш дәрәҗәсе 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а»—«г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә

социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә, 2019 елда аның күләме 486 сум тәшкил итә.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында әлеге карарның 2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацларда күрсәтелгән ялгыз яшәүче гражданнарның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләгәндә 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктчасы нигезендә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланыла дип каралган.

Нигезләмәнең 9.11 пункты нигезендә пенсионер үз милкендәге торак урынында торак урын милектәшләре булган һәм торак урын милектәшләре булмаган гаилә әгъзалары белән бергә яшәгәндә аңа транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү пенсионерга караган торак урын мәйданының күләме 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктында яки «б» пунктында гаилә әгъзасы өчен билгеләп күрсәтелгән мәйданның иң чик күләменнән артып китмәү шарты белән билгеләнә.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезендә гаиләнең (гражданның) мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе дигәндә гаилә әгъзаларының (гражданның) милкендә мәйданы гаиләнең һәрбер әгъзасына исәпләгәндә 40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган торак урын (торак урынның өлеше) булу аңлашыла.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданин Ч.В. Мәҗитов 2019 елның ноябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карары нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алучы булып торган. Әлеге түләү туктатылу сәбәпле ул Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына аңлатмалар сорап мөрәҗәгать иткән, аннан алынган җавап буенча 2019 елның 1 апреленнән үз көченә кергән 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр нигезендә аңа

транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тартылган. Кертелгән үзгәрешләр нигезендә пенсионерга, әгәр аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе милек хокукындагы торак урыны 40 квадрат метрдан артмаган булса, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнә. Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, әлеге үзгәрешләр 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нормаларына сылтама ясый, ул пенсионерларга социаль ярдәм чараларын бирүне регламентлаштырмый, бу исә, үз чиратында, аларга айлык акчалата түләү билгеләү турындагы мәсьәләне хәл иткәндә «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсен куллану мөмкинлегендә билгесезлек тудыра. Моннан тыш, кертелгән «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсе мондый тәэмин ителешне бәяләү барлык гаилә әгъзаларын да исәпкә алып башкарылуын күздә тота. Шуның белән бергә, Нигезләмәнең 9.11 пункты нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү турында карар кабул иткәндә пенсионерның гаилә әгъзалары исәпкә алынмый. Гражданин Ч.В. Мәҗитов санаганча, болар барысы да әлеге түләүне билгеләгәндә пенсионерның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү ни рәвешле башкарылуы турындагы мәсьәләдә билгесезлек тудыра.

Моннан тыш, ул югарыда аталган үзгәрешләр «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 7 мартындагы 163 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кертелгән иде, ул 5 пункт нигезендә 2019 елның 1 апрелендә үз көченә керде, дип билгеләп үтә. Мөрәҗәгать итүче санаганча, кертелгән үзгәрешләр аңа карата һәм 2019 елның 1 апреленә кадәр пенсиягә чыккан башка пенсионерларга карата кулланылмаска тиеш, башкача булуы законның кире көче турындагы кагыйдәгә каршы килер иде.

Шулай ук гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында ялгыз яшәүче гражданнарның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмы билгеләнгән, аның нигезендә мондый гражданга 40 квадрат метр

торак урыны түгел, ә 80 квадрат метр кулланылуына игътибар итә. Мөрәҗәгать итүче мондый алымны гаделсез һәм гаилә әгъзалары булган пенсионерларны һәм ялгыз пенсионерларны тигезсез хәлгә куя торган дип саный һәм пенсионер яши торган торак урын гаиләнең барлык әгъзаларына бүленмәсә, мондый аерма да булырга тиеш түгел дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Ч.В. Мәҗитов Татарстан Республикасы Конституция судыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацын, 2.1 пунктын һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктын «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты белән аларның үзара бәйләнешендә Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 38 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә кеше, аның хокуклары һәм ирекләре — иң зур хәзинә; кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау — Татарстан Республикасының бурычы; Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең теләсә кайсы рәвеше я аларга өстенлекләр билгеләү тыела; гаилә, ана булу, ата булу, балачак һәм

картлык дәүләт яклавында; һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара яисә киметә торган законнар чыгарылмаска тиеш.

1.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса, Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була дип билгеләнгән.

Әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Конституция суды утырышы барышында 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезләмәләре гражданин Ч.В. Мәҗитовка карата кулланылган яисә кулланылырга тиеш булуы расланмады, чөнки бу нигезләмәләр балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибенә кагыла һәм турыдан-туры пенсионерларга социаль ярдәм чаралары күрсәтү тәртибенә кагылмый.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 63 статьясы нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, утырыш барышында мөрәҗәгатьне карауга алудан баш тартуга нигезләр ачыкланса, шуларның берсе — аның мөмкин булу критерийларына туры килмәве ачыкланган очракларда эш алып баруны туктата.

Димәк, әлеге эш буенча 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты нигезләмәсенең конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш туктатылырга тиеш, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы тугызынчы өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды фәкать хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә бүтән органнар компетенциясенә кергән барлык очракларда фактлагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшерүдән тыелып кала.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану практикасындагы мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре алар пенсионерларга, шулай ук алар арасыннан ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләгәндә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмын билгеләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып тора.

2. Нигезләмәләренә карата гражданин Ч.В. Мәҗитов шикаять белдерә торган 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарны кабул итү буенча

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә кагылышлы мәсьәлә элегрәк Татарстан Республикасы Конституция судының тикшерү предметы булган иде, ул, күрсәтелгән норматив хокукый актны кабул итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы Конституциясендә, шулай ук федераль һәм республика законнарында каралган үз вәкаләтләре чикләрендә эш иткән дигән нәтиҗәгә килгән иде (2012 елның 4 июлендәге 49-П номерлы һәм 2013 елның 27 мартындагы 52-П номерлы карарлар). Татарстан Республикасы Конституция судының күрсәтелгән карарлары һәм аларда чагылдырылган хокукый позицияләр үз көчләрен саклый.

3. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясындагы беренче өлешенең «ж» пункты нигезендә социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый. Федераль закон белән Россия Федерациясендә чыгарылган башка акт арасында каршылык булганда, федераль закон гамәлдә була. (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясындагы 2 һәм 5 өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законда каралганча, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм

социаль булышуның өстәмә чараларын, шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел. Вәкаләтләрне әлеге статьяда каралган финанслау Россия Федерациясе субъекты бурычы булып тормый, мөмкинлек булганда гамәлгә ашырыла һәм федераль бюджеттан өстәмә акчалар бүлеп бирелү өчен нигез булып тормый (26.3-1 статьяның өченче һәм дүртенче өлешләре).

Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясы (беренче өлеш) белән үзара бәйләнештә 13 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм ирекле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт, һәркемгә яше буенча, авырган, гарипләнгән, туендыручысын югалткан очракта, балаларны тәрбияләү өчен һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә. Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 статьясындагы беренче өлеше буенча социаль тәэминат Татарстан Республикасы законында билгеләнгән очракларда һәм күләмнәрдә социаль ярдәм чараларын бирүне үз эченә ала. Мәгънәсе буенча шундый ук гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7 һәм 39 (беренче өлеш) статьяларында билгеләнгән.

Китерелгән конституциячел нигезләмәләрдән закон чыгаручының яше, сәламәтлеге яисә башка үзләреннән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшли алмаучылар өчен үз хокукларын гамәлгә ашыруда тиешле шартлар булдыруны һәм гражданнарның аеруча киеренке категориясенә ярдәм итүне тәэмин итәрлек социаль яклау системасын урнаштыру бурычы килеп чыга. Шул ук вакытта пенсионерларның матди тәэмин ителеш дәрәҗәсе алына торган пенсия суммасына гына түгел, ә социаль хезмәт күрсәтүләргә һәм төрле ташламалар булуга да бәйле.

Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позициясе нигезендә Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысы, аңа социаль яклау

өлкәсендә бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, киң дискрециягә ия һәм үз акчалары исәбеннән социаль ярдәм күрсәтүнең (булышуның) формасын, төрләрен һәм шартларын, шул исәптән адреслылык принцибын исәпкә алып һәм мохтаҗлыкны бәяләү нигезендә билгеләргә дә, шулай ук күрсәтелгән өлкәдә хокукый җайга салуны үзгәртергә дә хокуклы (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

3.1. Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашырып, республика закон чыгаручысы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба шулай ук — 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) Татарстан Республикасында гражданнарның адреслы социаль ярдәм чаралары күрсәтелә торган категорияләрен, шулай ук мондый ярдәмнең конкрет күләмнәрен һәм рәвешләрен билгеләгән. Социаль ярдәм чараларын алуга дәгъва итүче гражданнарның ихтыяҗларын тикшерү процедураларын камилләштерү һәм ярдәм бирүгә адреслы якын килүне арттыру максатларында закон чыгаручы югарыда аталган Законга кушымтада мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен билгеләү критерийларын раслаган.

Күрсәтелгән Законның 2 статьясындагы икенче өлеше нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән пенсионерларга социаль ярдәм күрсәтү чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган акчалар чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге норма нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацы белән пенсияләре «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә билгеләнгән, 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнарга, 2018 елның

31 декабре хәленә карата әлеге федераль законнар белән күздә тотылган пенсия билгеләү шартларына туры килә торган, әмма 60 һәм 55 яшькә (шул ук эзлеклелектә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән Татарстан Республикасында яшәүче гражданнарга, Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә социаль ярдәм чараларына хокуклары булмаган пенсионерларга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү бирелә дип билгеләнгән.

Үзенең хокукый табигате буенча күрсәтелгән карарда билгеләнгән хокукый җайга салу билгеләнеше федераль законнар нормаларына нигезләнгән социаль ярдәм чаралары исәбенә керми, ә тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган, билгеләнеше аерым категория гражданнарның матди иминлеген тәэмин итү булган максатчан характерга ия һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү чарасы булып тора, аны билгеләү — Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы. Бу аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисади үсешнең әлеге этабындагы финанс һәм башка матди мөмкинлекләрне исәпкә алып, гражданнарның адреслылык һәм бәяләү принципларында республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының шикаять белдерелә торган 2 пунктындагы икенче абзацы нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү, аерым алганда, пенсионерларга аларның уртача айлык керемнәре күләме 20 000 сумнан артмаган һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а»—«г», «е», «ж» пунктлары белән билгеләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән түбәнрәк булган очракта билгеләнә. Күрсәтелгән кушымтаның «а» пункты нигезендә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе дигәндә гаилә әгъзалары (граждан) милкендәге мәйданы гаиләнең һәрбер әгъзасына исәпләгәндә

40 квадрат метрдан артыграк туры килә торган торак урын (торак урынның өлеше) булу аңлашыла.

Транспортта йөргә айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү тәртибе Нигезләмәнең 9 бүлеге белән җайга салынган, ул түбәндәге эзлекле этапларны күздә тота: граждан тарафыннан Республика матди ярдәм күрсәтү (компенсация түләүләре) үзәгенә (алга таба — Үзәк бүлеге) әлеге түләүне билгеләү турында тиешле документларны кушып гариза бирелә (9.1 пункт); Үзәк бүлеге тарафыннан вәкаләтле оешмалардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында карала торган түләүне билгеләү өчен кирәкле мәгълүматлар алу (9.2 пункт); транспортта йөргә айлык акчалата түләү билгеләү яисә аны билгеләүдән баш тарту турында Үзәк бүлеге тарафыннан карар кабул итү; кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү (9.4 пункт).

Китерелгән хокукый җайга салудан күренгәнчә, гариза бирү этабында да, ведомствоара хезмәттәшлек этабында да мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән мөлкәт цензына туры килү-килмәве турында мәгълүмат җыю процессы бара. Шулай итеп, Нигезләмәнең 9.1 пункты нигезендә граждан транспортта йөргә айлык акчалата түләү билгеләү турындагы гаризага күчемсез мөлкәтнең Бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән күчемсез милек объектларына хокук билгели торган документлар күчермәләрен кушып бирә (алтынчы абзац). Нигезләмәнең 9.2 пункты нигезендә Үзәк бүлеге вәкаләтле оешмалардан ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында күчемсез мөлкәт булу турында (өченче абзац) билгеләнгән тәртиптә торак урынын яшәү өчен яраксыз дип тану турында мәгълүмат ала (бишенче абзац).

Аталган норматив нигезләмәләрне анализлау Үзәк бүлегенең транспортта йөргә айлык акчалата түләү билгеләү кысаларында үткәрелә торган гражданның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү эшчәнлеге турында сөйли. Шул ук вакытта Нигезләмәнең шикаять белдерелә торган 9.11 пунктының сүзгә-сүз эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүчегә милек хокукында булган һәм аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен

ачыклаганда исәпкә алынырга тиешле торак мәйданын билгеләгәндә, аның белән әлеге торак мәйданында бу торак урын милектәшләре булмаган гаилә әгъзаларының яшәү факты исәпкә алынмый.

Нигезләмәнең 9.4 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы буенча алынган күрсәтелгән документлар, шулай ук граждан алган керемнәр турында белешмәләр (9.1 пунктның дүртенче һәм бишенче абзацлары, 9.2 пунктның икенче һәм җиденче абзацлары), транспорт чаралары, үзйөрешле транспорт чаралары һәм техниканың башка төрләре булу турында мәгълүматлар (9.2 пунктның дүртенче абзацы), Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар һәм җыемнар буенча бурычлар булмау турында (9.2 пунктның алтынчы абзацы) нигезендә Үзәк бүлеге тарафыннан транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү йә аны билгеләүдән баш тарту турында карар кабул ителә.

Нигезләмәнең шул ук пункты белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләүдән баш тарту өчен нигезләр каралган. Мондый карар мөрәҗәгать итүченең мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензын арттыру — милектә 40 квадрат метрдан артык торак урыны булу сәбәпле кабул ителергә мөмкин (9.4 пунктның җиденче абзацы). Тиешле исәп-хисап Нигезләмәнең 9.1, 9.2 һәм 9.11 пунктлары белән билгеләнгән хокукый җайга салу кысаларында башкарыла һәм мөрәҗәгать итүченең мөлкәт белән тәэмин ителешен Үзәк бүлеге тарафыннан бәяләүнең нәтиҗәсе булып тора.

Шул рәвешле, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының һәм Нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре, аларның турыдан-туры эчтәлегеннән һәм хокукый мәгънәсеннән чыгып, транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү өчен пенсионерның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензына — торак урынының 40 квадрат метрдан да артмаска тиешлегенә туры килүе хокук бирүче шарт булуын билгели. Шул ук вакытта китерелгән нигезләмәләрнең системалы анализы шуны күрсәтә:

гражданга транспортта йөрү өчен айлык акчалата түләү билгеләү максатларында, аның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү кысаларында исәпкә алынырга тиешле торак урынын билгеләгәндә тиешле торак урынына милек хокукы гына карала. Димәк, башка затларның исәпкә алынучы торак урынына карата хокуклары каралмый, ягъни мөрәҗәгать итүченең торак урынында үзенең әлеге торак урынының милекчеләре булмаган гаилә әгъзалары белән яшәү факты исәпкә алынмый һәм аның мөлкәт белән тәэмин ителешен бәяләү нәтиҗәсенә йогынты ясый алмый, чөнки транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү персональләштерелгән (индивидуаль) характерга ия.

63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктына сылтаманы үз эченә алган 542 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 2 пунктындагы икенче абзацы нигезләмәләренең юридик конструкциясеннән күренгәнчә, әлеге карарның 2 пунктындагы икенче абзацының һәм Нигезләмәнең 9.11 пунктының хокукый мәгънәсе буенча транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү рәвешендәге социаль ярдәм чарасы үзе мөрәҗәгать итүченең шәхесе белән аерылгысыз бәйле булганга күрә ярдәм күрсәтү турыдан-туры гражданның (пенсионерның) керемнәренә һәм мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле. Мондый конструкция асылда «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсенең эчтәлеген тәшкил итүче аерым норматив-хокукый характеристикаларны алу ысулы булып тора. Әлеге техниканы куллану гражданнарга социаль гарантияләр бирүдә югарыда китерелгән хокукый җайга салуның нигезен тәшкил итүче төшенчә аппаратының һәм принциплар бергәлегенең бердәмлеген тәэмин итү максатын күздә тота. Карала торган сылтама пенсионерның милкендә Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт теркәвенә алынырга тиешле торак урын (торак урынның өлеше) булу өлешендә «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсе алынма булудан башка берни дә түгел. Мондый алынма үзеннән-үзе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, булган дискрецион вәкаләтләр нигезендә җайга

салынулы хокукый мөнәсәбәтләр үзенчәлекләреннән чыгып, шул ук вакытта мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе формулировкасының мәгънәле әһәмиятен саклап калып, «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсен үз эчтәлеге белән тулыландырырга хокуклы булуы белән бәйле.

Мондый нәтиҗә 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пункты үзеннән-үзе әлеге Законның 8 статьясындагы 7 өлешен гамәлгә ашыруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән, анда 18 яшькә кадәрге балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын билгели торган, әлеге статьяда турыдан-туры каралганча, ярдәм күрсәтү шул исәптән гаиләнең һәр әгъзасына караган мөлкәттән чыгып исәпләнгән мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә бәйле һәм әлеге нигезләмәне социаль ярдәм чаралары күрсәтүнең башка очракларына карата куллану аталган Закон белән җайга салынмавына да тәңгәл килә. Аерым алганда, анда әлеге Законга кушымтаның «а» пункты нигезләмәләрен пенсионерлар кебек гражданнар категориясенә карата куллануга турыдан-туры күрсәтмә юк.

Шуңа бәйле рәвештә мөрәҗәгать итүченең мондый төрдәге сылтама булу 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктында беркетелгән «мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе» төшенчәсенең эчтәлегеннән тайпылу мөмкинлегенә юл куймый дигән дәлилләре расланмый.

Китерелгән хокукый җайга салу белән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пункты аерылгысыз бәйле, ул әлеге карарның 2 пунктындагы икенче абзацында күрсәтелгән ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләнгән очракта аларның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләгәндә 40 квадрат метр урынына 80 квадрат метр кулланылуын күздә тота. Барлык пенсионерлардан ялгыз яшәүчеләрне аерып күрсәтү үзе үк мондый гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү мәсьәләсен хәл иткәндә, алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзасы тарафыннан алар исәп тота алырлык матди ярдәм булмау аерым әһәмияткә ия дигәнне аңлата. Башка

сүзләр белән әйткәндә, бу мәсьәләдә гражданның гаилә әгъзалары белән бергә яшәү яки яшәмәү шартларын бәяләү урынлы. Күрсәтелгәннәр гражданның матди хәле турында күзаллауны формалаштыруга карый. Шул ук вакытта гаиләнең бергә яшәүче әгъзасы тарафыннан тиешле ярдәм булмау, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты позициясеннән килеп чыга торган логика буенча, ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү булмауны тулыландыруның бер чарасы буларак шарт итеп куя. Әлеге искәрмәне күздә тотып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты ялгыз яшәүче гражданнар пенсионерларның аеруча киеренке категориясе булуыннан һәм аерым ярдәмгә мохтаҗ булуыннан чыгып эш иткән. Мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсе буенча мөлкәт цензын 80 квадрат метрга кадәр арттырып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты андый гражданнар өчен шуның белән транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алуга дәгъва итәргә мөмкинлек бирә торган өстенлек билгеләгән.

Бу Россия Федерациясе Конституция Суды позициясенә тулысынча туры килә, анда билгеләнгәнчә, законнарның мәгънәсен, эчтәлеген һәм кулланылышын, закон чыгару һәм башкарма хакимиятнең, җирле үзидарәнең эшчәнлеген билгели һәм гадел хөкем белән тәэмин ителә торган социаль дәүләтнең, барыннан да элек, кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклауга бурычлы гуманистик башлангычларыннан чыгып (Россия Федерациясе Конституциясенең 2 һәм 18 статьялары), закон чыгаручы гражданнарның аеруча киеренке категорияләренә, матди ярдәмне дә кертеп, дәүләт һәм җәмгыять ягыннан ярдәм алырга мөмкинлек бирерлек һәм шәхеснең дәүләт тарафыннан саклана торган абруен киметми торган (Россия Федерациясе Конституциясенең 21 статьясының беренче өлеше), яше, сәламәтлеге һәм башка үзеннән бәйле булмаган сәбәпләр аркасында эшли алмаучылар өчен үз хокукларын тормышка ашыруда уңайлы шартлар булдыруны тәэмин итәрлек шундый социаль яклау системасын булдырырга бурычлы (2013 елның 14 маендагы 9-П номерлы Карар).

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының 2.1 пунктында билгеләнгән хокукый җайга салу аның дискрецион вәкаләтләре чикләрендә кабул ителгән, үзенең хокукый табигате һәм максатчан билгеләнеше буенча пенсионерлар арасыннан аеруча киеренке категориягә керүче гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклауның өстәмә гарантияләрен (нигезләнгән өстенлекләрен) билгеләүгә, гавами-хокукый һәм хосусый-хокукый мәнфәгатьләр балансын тәэмин итүгә юнәлдерелгән һәм үзеннән-үзе кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен бозучы буларак карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәге нәтиҗәгә килә: Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацының, 2.1 пунктының һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктының үзара бәйле нигезләмәләре алар пенсионерларга, шулай ук алар арасыннан ялгыз яшәүче гражданнарга транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләгәндә мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен исәпләү механизмын билгеләгән дәрәҗәдә гражданнарның, шул исәптән гражданин Ч.В. Мәҗитовның да конституциячел хокукларын юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

Шуның белән бергә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый нигезләмәләрне Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип тану Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять бирелә торган хокукый җайга салуга гражданнарны ялгыз яшәүчеләр категориясенә кертү критерийларын төгәлләштерә торган, шул исәптән әлеге

хәлне раслау өчен пенсионерга нинди документлар тапшырырга кирәк булуын билгеләүче үзгәрешләр кертүгә комачауламый, чөнки әлеге эштә карала торган транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү тәртибе гражданны ялгыз яшәүче категориясенә кертүне ачык һәм төгәл итеп билгеләү механизмы нормаларда каралмаган. Мондый хокукый җайга салу социаль хокукый дәүләтнең асылына, шул исәптән гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын саклап калуның конституциячел принципларына җавап бирер иде.

3.2. Мөрәҗәгать итүченең дәгъва белдерелә торган нормаларга закон кире көчкә ия булмый дигән гомумхокукый принципны куллану турындагы дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Нигезләмәнең 9.5 пункты нигезендә транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү барлык кирәкле документлары белән гариза бирелгән айдан башлап билгеләнә һәм билгеләнгән айдан башлап алты ай дәвамында түләнә (беренче абзац). Аталган пунктның дүртенче абзацы нигезендә Үзәк бүлегендә пенсионерның транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү хокукын раслаучы мәгълүматлар булган очракта транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү аңа яңа срокка автомат рәвештә, аның мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.

Китерелгән хокукый җайга салу карала торган хокук мөнәсәбәтләренең мөрәҗәгать итүченең алты айдан соң транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алу хокукын раслау зарурлыгын күздә тоткан вакыт белән бәйле булуын күрсәтә. Бу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 542 номерлы карарының транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү билгеләү һәм түләү өлешендә гамәлдә булуы мөрәҗәгать итүче гариза биргән айдан һәм әлеге түләүне билгеләү турында карар кабул иткәннән соң башланган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм югарыда күрсәтелгән алты ай эчендә дәвам итә дигәнне аңлата. Алты ай узганнан соң транспортта йөрүгә айлык акчалата түләү алуны дәвам итү максатларында мөрәҗәгать итүченең вәкаләтләрен раслау зарурилыгын күздә тоткан әлеге хокук мөнәсәбәтләренең вакыт белән

бәйле булуы әлеге социаль ярдәм чарасының адреслылык принцибын үтәүне тәэмин итү гарантиясе булып тора һәм аңа мохтаҗ гражданнарга ярдәм итү мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән аспектта аның хокукларын бозучы буларак карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6, 63 статьяларына, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына, 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2004 елның 17 декабрендәге 542 номерлы карарының 2 пунктындагы икенче абзацын, 2.1 пунктын һәм әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында халыкның кайбер категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәнең 9.11 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

2. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а» пунктының конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эш буенча эш башкаруны туктатырга, чөнки мөрәҗәгать итүченең бу өлештә мөрәҗәгате мөмкин түгел.

3. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

4. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**106-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**